ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 649 24 октябрь,2017 ел

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының “2017 елның 1 сентябреннән Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тукландыруны оештыру турында” 25.07.2017, № 476нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруда һәм азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү максатыннан, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының “2017 елның 1 сентябреннән Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тукландыруны оештыру турында” 25.07.2017, № 476нчы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Карарның 2нче кушымтасындагы 2нче таблицадагы “Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында аерым категория балалар өчен туклану бәясе” дигән 1нче юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Ятим балалар, опекадагы балалар, инвалид балалар, Чернобыль АЭС һәлакәте калдыкларын ликвидацияләүдә катнашкан гаиләләрнең балалары, Татарстан Республикасында җан башына керемнәре яшәү минимумыннан түбәнрәк булган аз керемле, күп балалы (өч бала) гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар, шулай ук яшәү минимумына карамастан, күп балалы гаиләләрдә (4 һәм аннан артыграк бала) тәрбияләнүче балалар”.

2. Түбән Кама муниципаль районы бюджет һәм финанслар департаментына (Логинова С.Н.) Татарстан Республикасында җан башына керемнәре яшәү минимумыннан түбәнрәк булган аз керемле, күп балалы (өч бала) гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар, шулай ук яшәү минимумына карамастан, күп балалы гаиләләрдә (4 һәм аннан артыграк бала) тәрбияләнүче балаларны бушлай тукландыру өчен Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф идарәсенә бүлеп бирелгән бюджет ассигнованиеләре кысаларында финанслауны карарга һәм бушлай туклануны тәэмин итәргә;

3. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Р. Фәретдиновка йөкләргә.

А.Г. Сәйфетдинов